# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

**№ 3**

март

1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 3*

*март*

*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174 1996 елның 03.10 бирелде
Житештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1000 нөсхә. Заказы 0018-90
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н. Ершов ур., 31б.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хезмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы
© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 1999

Эчтәлек

# I

445.“Социаль партнерлык турында“ *Татарстан Республикасы Законы* .... 7

446.“Социаль партнерлык турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында“*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......... 18

447.“Татарстан Республикасы каршында аерым казанышлары булган гражданнарның дәүләт пенсиясенә өстәмә турында“*Татарстан Республикасы Законы* .......... 19

448.“Татарстан Республикасы каршында аерым казанышлары булган гражданнарның дәүләт пенсиясенә өстәмә турында” Татарстан Республикасы Законы хакында“*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......... 22

449.“Янгын куркынычсызлыгы турында”, “Татарстан Республикасы гражданнарын медицина иминләштерүе турында”, “Татарстан Республикасында юллар фонды турында”, “Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына кертемнәрнең 1997 елга иминлек тарифы турында” Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында“*Татарстан Республикасы Законы* .......... 23

450.“Янгын куркынычсызлыгы турында”, “Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминлеге турында”, “Татарстан Республикасында юллар фонды турында”, “Татарстан Республикасының эш белән тәэмин итү дәүләт фондына 1997 елга кертемнәрнең иминләштерү тарифы турында” Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законын кабат карау турында“ .......... 26

451.“Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......... 27

452.“Татарстан Республикасының Законнар җыентыгы турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......... 28

453.”Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларын сайлау турында“*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .... 28

454.“Россия Федерациясе Конституция Суды судьясы урынына кандидат турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......... 29

455.”1999-2000 елларга “Татарстан яшьләре” дәүләт программасы проектын эшләүне дәвам итү турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......... 29

456."1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотиклардан явыз нияттә файдалануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору комплекслы чаралары" республика максатчан программасын эшләүне дәвам итү турында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 30
457."Россия Федерациясе Җинаять кодексының 329 статьясына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 31
458."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кайбер даими комиссияләре составындагы үзгәрешләр турында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 31
459."Татпромстройбанк" кертемчеләре мөрәҗәгатьләрен караганда һәм мәнфәгатьләрен яклаганда законнарны үтәү турында" Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбе хакында "*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 32
460."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 24 мартындагы утырышы көн тәртибе турында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 33
461."Татарстан Республикасының кайбер район, шәһәр судлары судьяларын сайлау турында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 34
462."Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында "Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 35
463."Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында "*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 36
464."Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында файдалану хокукы бирелергә мөмкин булган нефть ятмалары исемлеге хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..... 36
465."Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 37
466."Россия Федерациясендә гомуми юрисдикция судлары турында" федераль конституциячел закон проекты хакында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 37
467."Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чараларын финанслау хакында" Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы турында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 40

468."Акча кертүчеләрнең кертемнәрен кайтару турында "Промстройбанк" банкының конкурслы идарәчесе мәгълүматы хакында "*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ............ 40

## II

469."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе эшен дәвам итү турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............ 41

470."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............ 41

471."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ..... 42

472."Татарстан Республикасы Дәүләт Советы язгы сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............ 43

473."1999 елның 24 мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............ 43

474."1999 елның 24 мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............ 44

475."Җирле үзидарә органнары вәкилләренең республика җыелышын үткәрү көне турында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............ 45

476."Гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыклары турында" Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау нәтиҗәләре турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............ 46

477."Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 12 февралендәге XVIII пленар утырышында әйтелгән тәкъдимнәр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ..... 46

478."Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 18 февралендәге утырышында әйтелгән тәкъдимнәр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............ 47

## III

479."Татарстан Республикасының җиңел һәм агач эшкәртү промышленносте предприятиеләренә дәүләт булышлыгы күрсәтү чаралары турында" *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .................. 49

480."Авиация промышленносте эшләре буенча Республика советы төзү турында" *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......... 50

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 445. Социаль партнерлык турында

Әлеге Закон, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм алар белән бәйле икътисадый мөнәсәбәтләрне җайга салу һәм җәмәгать килешүенә ирешү максатларында, Татарстан Республикасында социаль партнерлык системасының хокукый нигезләрен һәм аның эшчәнлегенең тәртибен билгели.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. **Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр**

Әлеге Законда түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

социаль партнерлык – хезмәткәрләрнең, эш бирүчеләрнең, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруның оптималь балансын тәэмин итүче һәм шул нигездә җәмгыятьтәге социаль тотрыклылыкка ирешүгә, җәмәгать үсешенә ярдәм итүче, үзара консультацияләрдә, сөйләшүләрдә, яклар тарафыннан килешүләргә, күмәк шартнамәләргә ирешүдә һәм төзүдә, уртак карарлар кабул итүдә чагылучы социаль-хезмәт мөнәсәбәтләренең һәм алар белән бәйле икътисадый мөнәсәбәтләрнең тибы;

социаль партнерлык яклары – сөйләшүләрдә катнашучы һәм килешүләр, күмәк шартнамәләр төзүче хезмәткәрләр, эш бирүчеләр, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары, вәкаләтле вәкилләре аша Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары;

социаль партнерлык системасы – даими эшләп килүче һәм социаль партнерлык яклары барлыкка китерүче органнар; үзара консультацияләр һәм сөйләшүләр нигезендә яклар тарафыннан кабул ителүче уртак документлар; социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре һәм алар белән бәйле икътисадый мөнәсәбәтләр,

социаль-хезмәт конфликтларын хәл итү өлкәсендәге оештыру, хокукый һәм икътисадый гамәлләр бергәлеге;

оешмалар – милек рәвешләренә һәм кемгә буйсынуларына карамастан, юридик затлар;

хезмәткәрләр – хезмәт шартнамәсе (контракт) нигезендә эшләүче физик затлар;

хезмәткәрләрнең вәкилләре – үз уставлары нигезендә вәкиллеккә вәкаләтле һөнәр берлекләре органнары һәм аларның берләшмәләре, хезмәткәрләрнең оешма хезмәткәрләренең гомуми җыелышында (конференциясендә) сайланган һәм вәкаләт тапшырылган үз вәкилләре. Һөнәр берлеге әгъзалары булмаган хезмәткәрләр күмәк сөйләшүләр барышында, күмәк шартнамә, килешү төзү, үзгәртү һәм өстәмәләр кертү һәм аларның үтәлешен тикшереп тору барышында аларның мәнфәгатьләрен чагылдыру өчен һөнәр берлеге органына вәкаләт тапшырырга мөмкин;

эш бирүчеләр – хезмәткәрләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы юридик һәм физик затлар;

эш бирүчеләрнең вәкилләре – оешмаларның җитәкчеләре яисә оешма уставы һәм норматив-хокукый актлар нигезендә вәкаләт тапшырылган затлар, эш бирүчеләр берләшмәләренең вәкаләтле органнары, эш бирүчеләр вәкаләт тапшырган башка органнар;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарының һәм җирле үзирадә органнарының вәкилләре – бу органнарның җитәкчеләре һәм нигезләмәләр, уставлар нигезендә вәкаләт тапшырылган башка затлар, бу органнар вәкаләт тапшырган бүтән затлар;

генераль килешү – Татарстан Республикасында социаль-икътисадый сәясәтне килешүле уздыруның гомуми принципларын билгеләүче хокукый акт;

республика тармак (тариф) килешүе – тармакның (тармакларның) социаль-икътисадый үсешенең төп юнәлешләрен, тармак (тармаклар) хезмәткәрләре, һөнәри төркемнәр хезмәте өчен түләү нормалары һәм башка хезмәт шартларын, социаль гарантияләр һәм өстенлекле ташламалар билгеләүче хокукый акт;

махсус территория килешүе – шәһәрнең, районның, үзләрендә җирле үзидарә гамәлдә булган территорияләрнең территория үзенчәлекләре белән бәйле билгеле бер социаль-икътисадый проблемаларын хәл итү шартларын, хезмәт

шартларын, социаль гарантияләрне һәм ташламаларны законнар нигезендә билгеләүче акт. Махсус территория килешүендә тиешле территориядә урнашкан оешмаларның барлык хезмәткәрләре яисә һөнәри төркемнәр өчен хезмәт шартлары, социаль гарантияләр һәм ташламалар билгеләнергә мөмкин.

2 статья. **Татарстан Республикасында социаль партнерлыкның хокукый нигезе**

Татарстан Республикасында социаль партнерлыкның хокукый нигезен Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, башка законнар һәм социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салучы бүтән төрле норматив-хокукый актлар, шул исәптән Генераль килешү, республика тармак (тариф) килешүләре, махсус территория килешүләре, законнар нигезендә төзелүче күмәк шартнамәләр тәшкил итә.

Әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, шул исәптән Хезмәтнең Халыкара Оешмасы конвенцияләре, шулай ук федераль законнар хезмәткәрләр өчен әлеге Законга караганда уңайлырак шартлар билгеләсәләр, ул чакта алда санап үтелгән халыкара шартнамәләрнең, килешүләрнең һәм федераль законнарның нормалары һәм кагыйдәләре кулланыла.

3 статья. **Әлеге Законның гамәлдә булу даирәсе**

Әлеге Закон түбәндәгеләргә кагыла:

оешмаларның хезмәткәрләренә, башлангыч, тармак һәм территория һөнәр берлекләре оешмаларына һәм аларның берләшмәләренә;

эш бирүчеләргә һәм аларның берләшмәләренә;

Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнарына, җирле үзидарә органнарына.

## II бүлек. Татарстан Республикасында социаль партнерлык системасы

4 статья. **Социаль партнерлык системасының бурычлары**

Татарстан Республикасында социаль партнерлык системасы түбәндәге төп бурычларны гамәлгә ашыру өчен булдырыла:

республиканың икътисадый һәм социаль үсешенә ярдәм итү;

килештерелгән социаль юнәлешле икътисадый сәясәтне әзерләүне һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм алар белән бәйле икътисадый мөнәсәбәтләрне җайга салуның нәтиҗәле механизмын тәэмин итү;

кумәк сөйләшүләр, үзара консультацияләр уздыру, социаль партнерлык системасы яклары арасында законнар нигезендә кумәк шартнамәләр, килешүләр төзү;

кумәк хезмәт бәхәсләрен булдырмый калу һәм социаль-хезмәт конфликтларын хәл итәргә ярдәм итү;

социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салуның закон чыгару базасын камилләштерү.

5 статья. **Социаль партнерлык системасының эшләү принциплары**

Социаль партнерлык системасы түбәндәге принципларда эш итә:

законнарны үтәү;

социаль партнерлык якларының һәм аларның вәкилләренең тулы вәкаләтле һәм тигез хокуклы булулары;

кумәк шартнамәләрнең һәм килешүләрнең эчтәлеген тәшкил итүче мәсьәләләрне сайлап алу һәм тикшерү иреге;

үзара килештерү нигезендә социаль партнерлык якларының йөкләмәләрне кабул итүләренең ихтыяри булуы;

социаль партнерлык яклары кабул иткән килешүләрнең, кумәк шартнамәләрнең һәм карарларның шартларын үтәүнең мәҗбурилеге;

социаль партнерлык яклары кабул итүче йөкләмәләрне тәэмин итүнең реаль булуы;

кабул ителгән шартнамәләрдәге һәм килешүләрдәге шартларның үтәлешен тикшереп торуның даимилеге;

кабул ителгән йөкләмәләрнең, килешүләрнең, кумәк шартнамәләрнең һәм карарларның үз гаепләре белән үтәлмәве өчен социаль партнерлык якларының һәм аларның вәкилләренең җаваплылыгы.

6 статья. **Социаль партнерлык системасы эшчәнлегенең механизмы**

Социаль партнерлык системасы түбәндәгеләргә таянып эш итә:

социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре һәм алар белән бәйле

икътисадый мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча социаль партнерлык якларының карашларын алдан өйрәнү һәм ачыклау йөзеннән аларның вәкаләтле вәкилләре уздыручы үзара консультацияләргә;

килеп чыгучы мәсьәләләрне һәм проблемаларны җайга салу йөзеннән, шул исәптән күмәк хезмәт бәхәсләрен законнар нигезендә хәл иткәндә социаль партнерлык якларының вәкаләтле вәкилләре уздыручы сөйләшүләргә;

социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу мәсьәләләре буенча күмәк шартнамәләр һәм килешүләр төзүгә, уртак карарлар кабул итүгә.

**7 статья. Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республиканың өч яклы комиссиясе**

Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салуны тәэмин итү, күмәк сөйләшүләр алып бару һәм Генераль килешү проектын әзерләү өчен социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республиканың даими эшләүче өч яклы комиссиясе төзелә, ул Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты вәкилләреннән, һөнәр берлекләренең республика берләшмәләре вәкилләреннән, эш бирүчеләрнең республика берләшмәләре вәкилләреннән тигез санда төзелә. Комиссия координаторы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республиканың өч яклы комиссиясе әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һөнәр берлекләренең республика берләшмәләре һәм эш бирүчеләрнең республика берләшмәләре вәкаләтле органнары раслаган нигезләмәгә таянып эшли.

Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республиканың өч яклы комиссиясенең төп вазыйфалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

республикада социаль юнәлешле килештерелгән икътисадый сәясәтне әзерләүгә һәм гамәлгә ашыруга ярдәм итү;

күмәк сөйләшүләр алып бару, Генераль килешү проектын әзерләү, аның буенча фикер алышуны һәм аны төзүне оештыру;

тармакларның, төбәкләрнең үзенчәлекләрен һәм

гомумреспублика мәнфәгатьләрен исәпкә алып, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм аларга бәйле икътисадый мөнәсәбәтләрне җайга салуны координацияләү максатларында республика тармак (тариф) килешүләрен, махсус территория килешүләрен килештерү;

Генераль килешү, республика тармак (тариф) килешүләре, махсус территория килешүләре, күмәк шартнамәләр үтәлешен тикшереп тору;

килешүләрне һәм күмәк шартнамәләрне үтәмәүче затларны җаваплылыкка тарту турындагы тәкъдимнәрне законнарда билгеләнгән тәртиптә кертү;

килешүләр һәм күмәк шартнамәләр төзү һәм гамәлгә ашыру буенча булган каршылыкларны хәл итүгә ярдәм күрсәтү;

социаль-хезмәт мөнәсәбәтләренә һәм аларга бәйле икътисадый мөнәсәбәтләргә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарының һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары тарафыннан кабул ителүче башка норматив-хокукый актларның проектлары буенча фикер алышу, тиешле органнарга тәкъдимнәр кертү;

үз компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү, алар Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары, һөнәр берлекләре оешмалары һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең берләшмәләре каравы өчен мәҗбүри.

8 статья. **Татарстан Республикасында социаль партнерлык системасының башка органнары**

Килешүләр, күмәк шартнамәләр яклары үзара сөйләшеп килешүләр һәм бергәләп билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә, социаль партнерлык үсешенә, аерым юнәлешләр һәм проблемалар буенча Татарстан Республикасында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм аларга бәйле икътисадый мөнәсәбәтләрне җайга салуга ярдәм итә торган башка төрле өч яклы, ике яклы органнар төзергә мөмкин.

## III бүлек. Килешүләр һәм күмәк шартнамәләр

9 статья. **Генераль килешү**

Генераль килешү Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, һөнәр берлекләренең республика берләшмәләре

һәм эш бирүчеләрнең республика берләшмәләре белән чираттагы финанс елына Татарстан Республикасының республика бюджеты турында Татарстан Республикасы законын кабул иткәнче төзелә.

Генераль килешүдәге шартлар, законнар, Федераль Генераль килешү белән чагыштыргандагыдан хезмәткәрләрнең хәлен начарайта алмыйлар, һәм ул шартлар Татарстан Республикасының тиешле законнарын, бүтән норматив-хокукый актларын кабул иткәндә, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салуның барлык дәрәҗәләрендә, шул исәптән чираттагы финанс елына республика бюджеты турында Татарстан Республикасы законын караганда һәм кабул иткәндә, шулай ук республика тармак (тариф) һәм махсус территория килешүләрен, күмәк шартнамәләрне төзегәндә исәпкә алыналар.

Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республиканың өч яклы комиссиясе тарафыннан әзерләнгән Генераль килешү проекты килешүгә имза салу турында карар кабул итү өчен яклар вәкаләт тапшырган органнар каравына кертеләләр.

Генераль килешүгә имза салу турында Генераль килешү яклары карар кабул иткәннән соң өч көн эчендә Генераль килешүгә имза салынырга тиеш. Генераль килешүгә имза салу мизгеле аны төзү буенча күмәк сөйләшүләр тәмамланган мизгел була. Генераль килешү аңа имза салынган көненнән йә килешүдә билгеләнгән көннән үз көченә керә.

Генераль килешү имза салынганнан соң ун көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарларының рәсми басмасы рәвешендә массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

Генераль килешүнең гамәлдә булуы Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарына, җирле үзидарә органнарына, шулай ук үз исемнәреннән килешү төзергә үз вәкилләренә вәкаләт тапшырган хезмәткәрләргә һәм эш бирүчеләргә кагыла. Генераль килешүнең гамәлдә булуы шулай ук килешү басылганнан соң утыз көн эчендә аның эчтәлеге белән килешмәүләре хакында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республиканың өч яклы комиссиясенә язмача хәбәр итмәгән башка барлык оешмаларга да кагыла.

Генераль килешүнең гамәлдә булу чоры килешүче яклар тарафыннан билгеләнә, ул өч елдан да артык була алмый.

10 статья. **Республика тармак (тариф) килешүләре**

Республика тармак (тариф) килешүләре, тиешле чорга Генераль килешү төзелгәннән соң, тиешле министрлыклар, дәүләт комитетлары, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең башка төрле республика органнары, һөнәр берлекләренең республика тармаклары (аларның берләшмәләре), эш бирүчеләрнең республика тармак берләшмәләре арасында төзеләләр.

Республика тармак (тариф) килешүләрендәге шартлар хезмәткәрләрнең хәлен законнар, тиешле чорга Генераль килешү, гомумроссия тармак (тариф) килешүләре белән чагыштыргандагыдан начарайта алмыйлар.

Республика тармак (тариф) килешүләре тиешле норматив-хокукый актлар кабул иткәндә исәпкә алыналар.

Республика тармак (тариф) килешүләренең яклар тарафыннан хупланылган проектлары килештерү өчен Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республиканың өч яклы комиссиясенә җибәреләләр, шуннан соң аларга өч көн эчендә имза салынырга тиеш. Килешүләргә имза салу мизгеле аларны төзү буенча күмәк сөйләшүләр тәмамланган мизгел була. Килешүләргә яклар имза салган көннән йә килешүләрдә билгеләнгән көннән килешүләр үз көченә керә.

Республика тармак (тариф) килешүләренең гамәлдә булуы үз исемнәреннән килешү төзү өчен үз вәкилләренә вәкаләт тапшырган хезмәткәрләргә, эш бирүчеләргә, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарына кагыла.

Республика тармак (тариф) килешүенә имза салган Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органы вәкиле килешү төзүдә катнашмаган оешмаларның эш бирүчеләренә һәм хезмәткәрләренә үзләренә кушылырга тәкъдим ясарга хаклы, әмма бу оешмаларда килешү төзелүче шушы тармакка, һөнәргә караучы хезмәткәрләр кимендә 50 процент булырга тиеш. Әгәр эш бирүчеләр яисә хезмәткәрләрнең тиешле вәкилләре тәкъдим алынганнан соң 30 календарь көн эчендә килешүгә кушылу белән килешмәүләре турында хәбәр итмәсәләр, килешүнең гамәлдә булуы тәкъдим алынган мизгелдән шушы эш бирүчеләргә һәм хезмәткәрләргә дә кагыла.

Республика тармак (тариф) килешүенең гамәлдә булу

чоры килешүләрнең яклары тарафыннан билгеләнә, әмма ул өч елдан да артык була алмый.

11 статья. **Махсус территория килешүләре**

Махсус территория килешүләре һөнәр берлекләренең тиешле территория (тармак) берләшмәләре, эш бирүчеләрнең территория (тармак) берләшмәләре һәм җирле администрацияләр яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары арасында тиешле чорга Генераль килешү һәм республика тармак (тариф) килешүләре төзелгәннән соң төзеләләр.

Махсус территория килешүләрнең эчтәлеге килешү яклары тарафыннан билгеләнә һәм хезмәткәрләрнең хәлен законнар, Генераль килешү һәм республика тармак (тариф) килешүләре белән чагыштыргандагыдан начарайта алмыйлар.

Махсус территория килешүләре тиешле норматив-хокукый актлар һәм җирле бюджетлар кабул иткәндә исәпкә алыналар.

Махсус территория килешүләренең яклар тарафыннан хупланылган проектлары килештерү өчен Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республиканың өч яклы комиссиясенә җибәреләләр, шуннан соң аларга өч көн эчендә имза салынырга тиеш. Килешүләргә имза салу мизгеле аларны төзү буенча күмәк сөйләшүләр тәмамланган мизгел була. Махсус территория килешүләренә килешүләрнең яклары имза салган көннән йә килешүләрдә билгеләнгән көннән килешүләр үз көченә керә.

Махсус территория килешүенең гамәлдә булуы үзләре исеменнән килешү төзү өчен үз вәкилләренә вәкаләт тапшырган хезмәткәрләргә, эш бирүчеләргә, җирле администрацияләргә, җирле үзидарә органнарына кагыла.

Махсус территория килешүенә имза салган җирле администрация яисә җирле үзидарә органы вәкиле килешү төзүдә катнашмаган оешмаларның эш бирүчеләренә һәм хезмәткәрләренә аларга кушылырга тәкъдим ясый. Әгәр эш бирүчеләр яисә хезмәткәрләрнең тиешле вәкилләре тәкъдим алынганнан соң 30 календарь көн эчендә килешүгә кушылу белән килешмәүләре турында хәбәр итмәсәләр, килешүнең гамәлдә булуы тәкъдим алынган мизгелдән шушы эш бирүчеләргә һәм хезмәткәрләргә дә кагыла.

Махсус территория килешүләренең гамәлдә булу чоры

килешүләрнең яклары тарафыннан билгеләнә, әмма ул өч елдан да артык була алмый.

12 статья. **Килешүләрнең гамәлдә булу даирәсе**

Хезмәткәрләргә бер үк вакытта берничә килешү кагылган очракларда, хезмәткәрләр өчен иң уңайлы шартлары булган килешү гамәлдә була.

Генераль килешү (республика тармак (тариф) һәм махсус территория килешүләре) төзүдә вәкаләтле үз вәкилләре аша катнашмаган хезмәткәрләр һәм эш бирүчеләр, тиешле якның йөкләмәләрен үзенә алу нияте һәм кабул итүе хакында һәр якка язмача хәбәр итеп, тиешле килешүгә кушыла алалар.

13 статья. **Күмәк шартнамәләр**

Татарстан Республикасы территориясендә күмәк шартнамәләр "Күмәк шартнамәләр һәм килешүләр турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзеләләр һәм гамәлдә булалар.

14 статья. **Килешүләрне, күмәк шартнамәләрне алдан хәбәр итеп теркәү**

Социаль партнерлык яклары имза салган килешүләр, күмәк шартнамәләр эш бирүчеләрнең (эш бирүчеләр берләшмәләренең) вәкилләре тарафыннан җиде көн эчендә алдан хәбәр итеп теркәү өчен хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү буенча республика органына җибәрелә.

Шундый ук тәртип кабул ителгән килешүләргә һәм күмәк шартнамәләргә үзгәрешләр яисә өстәмәләр керткән очракта да гамәлдә була.

## IV бүлек. Социаль партнерлык системасы субъектларының хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы

15 статья. **Күмәк сөйләшүләр алып бару, күмәк шартнамәләр һәм килешүләр төзү хокукы**

Социаль партнерлыкның теләсә кайсы ягы тиешле дәрәҗәдә Генераль килешүне, республика тармак (тариф) килешүләрен, махсус территория килешүләрен, күмәк шартнамәләрне әзерләү, төзү һәм үзгәртү турындагы сөйләшүләрнең инициаторы булу хокукына ия.

Килешүгә яисә күмәк шартнамәләргә кертелгән мәсьәләләр буенча яклар үзара ризалык буенча аерым махсус карарлар кабул итәргә мөмкин.

Социаль партнерлык системасының килешү, күмәк шартнамә әзерләү, төзү һәм үзгәртү буенча сөйләшүләрнең башлануы турында башка яктан язмача тәкъдим алган ягы язмача хәбәр алганнан соң җиде көннән дә соңга калмыйча сөйләшүләр башларга тиеш.

16 статья. **Мәгълүмат алу хокукы**

Социаль партнерлык системасы яклары башка якка язмача таләп җибәргәннән соң ун көннән дә соңга калмыйча сөйләшүләр алып бару, килешүләр һәм күмәк шартнамәләр төзү һәм аларны гамәлгә ашыруны тикшереп тору өчен алардан кирәкле социаль-хезмәт мәсьәләләре буенча мәгълүмат алырга хокуклы. Хезмәт итү һәм коммерция сере булган мәгълүматны бирү законнар белән җайга салына.

17 статья. **Килешүләрнең, шартнамәләрнең предметын тәшкил итүче мәсьәләләрне караганда катнашу һәм тиешле мәгълүматны тарату хокукы**

Социаль партнерлык яклары күмәк сөйләшүләр алып бару, килешүләр һәм күмәк шартнамәләр төзү, аларны гамәлгә ашыру һәм аларның үтәлешен тикшереп тору барышында сөйләшүләрнең, килешүләрнең, күмәк шартнамәләрнең предметын тәшкил итүче мәсьәләләрне караганда башка якларның җитәкче органнары утырышларында, киңәшмәләрендә катнашырга хокуклы.

Һөнәр берлекләре, аларның оешмалары һәм берләшмәләре, эш бирүчеләр, аларның берләшмәләре сөйләшүләрнең һәм килешүләрнең предметын тәшкил итүче мәсьәләләрне, аларны төзү һәм үтәү мәсьәләләрен караганда дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат таратырга хокуклы.

18 статья. **Социаль партнерлык системасы эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү бурычлары**

Социаль партнерлык системасы эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү өчен кирәкле финанс чыгымнары социаль партнерлык яклары исәбеннән башкарыла.

19 статья. **Социаль партнерлык өлкәсендә җаваплылык**

Генераль килешүне, республика тармак (тариф) килешүләрен, махсус территория килешүләрен, күмәк шартнамәләрне төзү, үзгәртү һәм аларга өстәмәләр кертү турындагы сөйләшүләрдә катнашудан баш тарткан өчен, кабул иткән йөкләмәләрне үтәмәгән һәм бозган өчен яклар законнар нигезендә җаваплы булалар.

Әгәр килешүләрдә, күмәк шартнамәләрдә социаль партнерлык якларының мөлкәти йөкләмәләре булса, алар үтәлмәгән очракта җаваплылык Россия Федерациясенең граждани законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән өчен якны (якларны) җаваплылыкка тарту аларны килешү, күмәк шартнамә буенча булган йөкләмәләрен үтәү зарурлыгыннан азат итми.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 феврале
№ 2004

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 446. "Социаль партнерлык турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

"Социаль партнерлык турында" Татарстан Республикасы Законын басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 феврале
№ 2005

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 447. Татарстан Республикасы каршында аерым казанышлары булган гражданнарның дәүләт пенсиясенә өстәмә турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы каршында аерым казанышлары булган Татарстан Республикасы гражданнарының дәүләт пенсиясенә ай саен өстәмә түләү нигезләрен, аны билгеләү һәм түләү тәртибен регламентлаштыра.

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Дәүләт пенсиясенә ай саен өстәмә түләү (алга таба - өстәмә дип аталачак) Татарстан Республикасы каршында дәүләт корылышы, хуҗалык һәм социаль-мәдәни корылыш өлкәләрендә аерым казанышлары булган Татарстан Республикасы гражданнарына билгеләнә.

Татарстан Республикасы каршында аерым казанышлары булган гражданнарга (алга таба - гражданнар дип аталачак) өстәмә түбәндәге шартларда билгеләнергә мөмкин:

гомуми нигезләрдә картлык буенча дәүләт пенсиясе билгеләү өчен җитәрлек гомуми эш стажы һәм өстәмә билгеләү хакында үтенечнамә җибәрелгәндә исәпкә алынган Татарстан Республикасының җаваплы урыннарында кимендә 10 ел эш стажы булганда;

Татарстан Республикасының, Россия Федерациясенең һәм элеккеге СССРның дәүләт бүләкләре, мактаулы исемнәре булганда;

түләүле эшчәнлеген (эшен) туктатып, закон нигезендә пенсиягә чыкканда.

2 статья. **Өстәмәнең күләме**

Өстәмәнең күләме хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасында билгеләнәгән 0,5 тән алып 3 минималь күләменә кадәр билгеләнә.

Өстәмәне һәм аның күләмен билгеләү, гражданның казанышларын исәпкә алып, шәхсән башкарыла.

Әлеге Закон нигезендә өстәмә алу һәм бер үк вакытта Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт пенсиясенә башка төрле өстәмәләр алу хокукына ия булган гражданнарга, аларның теләге буенча, күрсәтелгән өстәмәләрнең берсе билгеләнә.

3 статья. **Өстәмәне билгеләү тәртибе**

Өстәмә түләү Татарстан Республикасы каршында аерым казанышлары булган гражданнарның дәүләт пенсиясенә өстәмә турындагы мәсьәләләрне карау комиссиясе (алга таба - Комиссия) тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

Комиссиянең персональ составы һәм аның турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы Президенты Указы белән раслана.

Өстәмә түләүне билгеләү өчен кирәкле документлар исемлеге, аларны бирү һәм карау тәртибе Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана торган Нигезләмә белән билгеләнә.

Өстәмә хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасында билгеләнгән 3 минималь күләменнән артык булмаган күләмдә дәүләт пенсиясе алучы затларга билгеләнә.

4 статья. **Өстәмә билгеләү турында үтенечнамә**

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, шул исәптән иҗат берлекләре, Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе өстәмә билгеләү хакында үтенечнамә белән чыгалар.

Министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, шул исәптән иҗат берлекләре, Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе тарафыннан бирелгән үтенечнамәләр мөрәҗәгать итүче яши торган урын буенча район (шәһәр) администрациясенә җибәрелә. Район (шәһәр) администрациясе барлык документларны алга таба Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим итү өчен Комиссиягә җибәрә.

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Миинистрлар кабинеты тарафынан бирелүче үтенечнамәләр алга таба Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим итү өчен Комиссиягә җибәрелә.

5 статья. **Өстәмәне исәпләү**

Өстәмә аны билгеләү хакында Татарстан Республикасы

Президенты Указына имза салынган көннән исәпләнә.

6 статья. **Өстәмәдән мәхрүм итү**

Өстәмә билгеләнгән гражданга карата законлы көченә кергән хөкем карары чыгарылганда, шулай ук өстәмә билгеләү өчен нигез булган белешмәләрнең дөрес булмавы ачыкланганда, өстәмә бетерелә.

Өстәмә билгеләү өчен нигез булган белешмәләрнең дөрес булмавы ачыкланганда, түләнгән суммалар өстәмә түләүне башкаручы орган карары буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә тотылып калырга тиеш.

Өстәмәдән мәхрүм итү Комиссия тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла.

7 статья. **Өстәмә түләүне туктатып тору**

Өстәмә алучы граждан түләүле эшчәнлегенә (эшкә) яңадан керешкәндә, өстәмә алучы түләүле эшчәнлегенә керешкән айдан соң килүче айның беренче көненнән өстәмә түләү туктатып торыла.

Түләүле эшчәнлек туктатылганнан соң өстәмә түләү киләсе айның беренче көненнән кабат яңартыла.

Өстәмә түләүне туктатып тору һәм кабат яңарту, дәүләт пенсиясенә өстәмә билгеләнгән гражданның гаризасы нигезендә яшәү урынындагы дәүләт пенсияләрен түләү буенча вәкаләтле органнар тарафыннан башкарыла.

8 статья. **Өстәмә түләү билгеләнгән гражданнарның вазыйфалары**

Өстәмә түләү билгеләнгән гражданнар үзләренең түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнә башлаулары (эшкә урнашулары) хакында дәүләт пенсияләрен түләү буенча вәкаләтле органга хәбәр итәргә тиеш. Әлеге статьяда күрсәтелгән шартны бозган очракта, артык түләнгән акчалар законнарда билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

9 статья. **Өстәмә түләү чаралары**

Гражданнарга өстәмә түләү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының махсус счетыннан башкарыла. Әлеге счет түбәндәге чаралардан барлыкка китерелә:

Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары;

җирле бюджетларның дәүләт хакимиятенең һәм идарә-

сенең җирле органнары карары нигезендә дәүләт пенсияләренә өстәмә түләү максаты белән җибәрелә торган акчалары;

предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмаларның өстәмә түләү өчен билгеләнгән тәртиптә җибәрелүче акчалары;

законнар белән тыелмаган башка төрле чыганаклар.

Керә торган акчалар Татарстан Республикасы Социаль тәэминат министрлыгы счетына күчерелә, шуннан өстәмә түләү башкарыла.

10 статья. **Өстәмәне түләү**

Өстәмә гражданнарның яшәү урыннарында дәүләт пенсияләрен түләү буенча вәкаләтле органнар тарафыннан дәүләт пенсиясе белән бергә түләнә, һәм алардан салым алынмый. Өстәмә Татарстан Республикасында даими яшәүче затларга түләнә. Даими яшәү өчен Татарстан Республикасыннан читкә киткәндә өстәмә түләү туктатып торыла.

11 статья. **Законны гамәлгә кертү**

Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үзләренең норматив-хокукый актларын шушы Законга туры китерергә, дәүләт пенсиясенә ай саен бирелүче өстәмәне билгеләү һәм түләү мәсьәләләрен җайга салучы кирәкле норматив-хокукый актлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2040

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 448. “Татарстан Республикасы каршында аерым казанышлары булган гражданнарның дәүләт пенсиясенә өстәмә турында” Татарстан Республикасы Законы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**
Татарстан Республикасы каршында аерым казанышлары

булган гражданнарның дәүләт пенсиясенә өстәмә турында" Татарстан Республикасы законын, 5 статьяны редакцияләп, кабат кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2041

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 449. "Янгын куркынычсызлыгы турында", "Татарстан Республикасы гражданнарын медицина иминләштерүе турында", "Татарстан Республикасында юллар фонды турында", "Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына кертемнәрнең 1997 елга иминлек тарифы турында" Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

1 статья. "Янгын куркынычсызлыгы турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, № 11-12; 1994 ел, №1-2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996 ел, №2) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

43 статьяның 1 пункты 5 бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) янгынга каршы күчмә техникалы янгыннан саклаучы объект бүлекчәләре булмаган төрле милек рәвешләрендәге (бюджет оешмаларыннан тыш) предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның янгынга каршы дәүләт хезмәтен тоткан өчен түләмнәрен төп чараларның, төгәлләнмәгән төзелешнең, чималның, материалларның һәм башка шуңа охшаш кыйммәтләрнең, үрчетелә һәм симертелә торган хайваннарның, арзанлы һәм тиз тузучы предметларның калган хакыннан, төгәлләнмәгән җитештерүдәге, әзер продукция, алып-сату товарлары чыгымнарыннан, бүтән төрле запаслардан һәм чыгымнардан 0,15 процент күләмендәге ставка буенча".

2 статья. "Татарстан Республикасы гражданнарын

медицина иминләштерүе турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994 ел, №1-2) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

7 статьяның 1 һәм 6 өлешләрен төшереп калдырырга; 3 өлешендә "эшләмәүче гражданнар өчен" дигән сүзләрдән соң "дәүләт идарәсенең җирле органнары тарафыннан" дигән сүзләрне өстәргә;

13 статьяның 11 өлешен төшереп калдырырга;

14 статьяның 4 өлешенә түбәндәге редакциядә 10 һәм 11 пунктлар өстәргә:

"10) мәҗбүри медицина иминләштерүе өчен иминлек кертемнәре һәм түләмнәре җыюны оештыру;

мәҗбүри медицина иминләштерүе системасына идарә итү".

3 статья. "Татарстан Республикасында юллар фонды турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992 ел, № 3; 1993 ел, № 3; 1994 ел, № 1-2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995 ел, №7-8; 1995 ел, № 9; 1996 ел, № 7; 1997 ел, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 статьяның 1 өлешендәге 5 абзацында "(гражданнар тарафыннан шәхси файдалануга сатып алынучы җиңел автомобильләрдән гайре)" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

4 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Милек рәвешләренә, нинди ведомствога буйсынуларына һәм оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, берләшмәләр, оешмалар, учреждениеләр һәм хуҗалык итүче башка субъектлар өчен ягулык-майлау әйберләрен (автобензин, дизель ягулыгы, майлар, мотор ягулыгы сыйфатында файдаланылучы тыгызландырылган һәм сыекландырылган газ) сатуга салым сату суммаларының 25 проценты күләмендә (акчага күчереп исәпләгәндә) билгеләнә, моңа өстәлгән бәяләргә салым керми";

7 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Автотранспорт чаралары сатып алуга салымны автотранспорт чараларын сатып алу - сату, алмашу, лизинг юлы белән Татарстан Республикасыннан читтә алган физик затлар, шулай ук автотранспорт чараларын сатып алу - сату, алмашу, лизинг һәм устав фондына кертем кертү юлы белән

алган юридик затлар түлиләр.

Салым автотранспорт чарасын теркәү яисә кабат теркәү урынында түләнә";

7 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

"2. Автотранспорт чаралары сатып алуга салым ставкасы түбәндәге күләмдә билгеләнә:

юридик затлар өчен - сату бәясеннән 5% (өстәлгән бәяләргә салымнан һәм акцизлардан тыш);

физик затлар өчен - Татарстан Республикасыннан читтә сатып алынган автотранспорт чараларының сату бәясеннән 3%";

7 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

"4. Салым түләүдән түбәндәгеләр азат ителәләр:

Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, өч дәрәҗәдәге Дан ордены белән бүләкләнгән гражданнар, өч дәрәҗәдәге Хезмәт Даны ордены белән бүләкләнгән гражданнар;

Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнар "Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында" 1991 елның 15 маендагы РСФСР Законы (шуннан соңгы үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән) нигезендә;

социаль тәэминат органнары аша мотоколяскалар һәм автомобильләр алган барлык категориядәге инвалидлар;

бюджеттан дотацияләр алучы, пассажирлар йөртүче (таксидан гайре) автотранспорт чаралары буенча гомуми файдаланудагы автотранспорт предприятиеләре".

4 статья. "Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына кертемнәрнең 1997 елга иминлек тарифы турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997 ел, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

Законның исемендә һәм текстында "1997 елга" дигән сүзләрне "1999 елга" дигән сүзләргә алыштырырга;

1 статьяның 1 абзацында "ике процент күләмендә" дигән сүзләрне "1,5 процент күләмендә" дигән сүзләргә алыштырырга;

3 статьяга "Татарстан Республикасының Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт комитеты" дигән

сүзләрдән соң “Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы” дигән сүзләр өстәргә, аннан соң текст буенча.

5 статья. Әлеге Закон матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2042

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 450. “Янгын куркынычсызлыгы турында”, “Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминлеге турында”, “Татарстан Республикасында юллар фонды турында”, “Татарстан Республикасының эш белән тәэмин итү дәүләт фондына 1997 елга кертемнәрнең иминләштерү тарифы турында” Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законын кабат карау турында

“Янгын куркынычсызлыгы турында”, “Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминлеге турында”, “Татарстан Республикасында юллар фонды турында”, “Татарстан Республикасының эш белән тәэмин итү дәүләт фондына 1997 елга кертемнәрнең иминләштерү тарифы турында” Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Президенты кире кайтарган Татарстан Республикасы законын караганнан соң Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

“Янгын куркынычсызлыгы турында”, “Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминлеге турында”, “Татарстан Республикасында юллар фонды турында”, “Татарстан Республикасының эш белән тәэмин итү дәүләт фондына 1997 елга кертемнәрнең иминләштерү тарифы турында” Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законын,

Татарстан Республикасы Президентының исәпкә алынган искәрмәләре һәм редакция төгәллекләре белән кабат кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2043

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 451. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе көн тәртибенә түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1."Татарстан Республикасының Законнар җыентыгы турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

2.1999-2000 елларга "Татарстан яшьләре" Дәүләт программасы проекты турында.

3."1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотиклардан явыз ниятләрдә файдалануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы торуның комплекслы чаралары" Республика максатчыл программасы проекты турында.

4.Россия Федерациясе Җинаять кодексының 329 статьясына үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

5.Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды судьяларын сайлау турында.

6.Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кайбер даими комиссияләре составындагы үзгәрешләр турында.

7."Татарстан Республикасы каршында аерым казанышлары булган гражданнарның дәүләт пенсиясенә өстәмә турында" Татарстан Республикасы Законы хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2031

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 452. "Татарстан Республикасының Законнар җыентыгы турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Татарстан Республикасының Законнар җыентыгы турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке хокукый каршылыкларны бетерү, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китереп, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен билгеләү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2033

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 453. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьялары итеп түбәндәгеләрне сайларга:

Габдрахманов Илгиз Илдус улын; Гыйльманова Эльмира Георгиевнаны; Камалетдинов Мансур Минабетдин улын; Петров Алексей Леонидовичны.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2032

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 454. Россия Федерациясе Конституция Суды судьясы урынына кандидат турында

Россия Федерациясе Конституция Суды судьясы вакансиясе ачылу белән бәйле рәвештә һәм “Россия Федерациясе Конституция Суды турында” Федераль конституция законының 9 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Россия Федерациясе Президентына Россия Федерациясе Конституция Суды судьясы урынына 1950 елда туган, татар, югары юридик белемле, юридик фәннәр кандидаты, Түбән Кама шәһәр суды судьясы, Татарстан Республикасы халык депутаты Миңнефаик Харис улы Вафин кандидатурасы турында тәкъдим кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2034

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 455. 1999-2000 елларга “Татарстан яшьләре” дәүләт программасы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. 1999-2000 елларга “Татарстан яшьләре” дәүләт программасын икенче укылышта кабул итәргә.

2 1999-2000 елларга “Татарстан яшьләре” дәүләт программасын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке хокукый каршылыкларны бетерү, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китереп, бүлекләрнең үзара дөрес бәйләнешен булдыру, өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт

Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты

№ 2035

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 456. "1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотиклардан явыз нияттә файдалануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору комплекслы чаралары" республика максатчан программасын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотиклардан явыз нияттә файдалануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору комплекслы чаралары" республика максатчан программасын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдимнәрне, кисәтүләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге программага төзәтмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә 1999 елның 12 апреленә кадәр кертелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе 1999 елның 12 маена кадәр, кертелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып әлеге программаны эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышка карауга тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2036

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 457. "Россия Федерациясе Җинаять кодексының 329 статьясына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1."Россия Федерациясе Җинаять кодексының 329 статьясына үзгәрешләр кертү турында" федераль закон проектын, аңлатма язуы белән бергә (кушымта итеп бирелә), Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) органнарыннан күрсәтелгән федераль закон проектын хуплауларын сорарга.

3. Әлеге карар проектының үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшинга йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2037

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 458. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кайбер даими комиссияләре составындагы үзгәрешләр турында

Татарстан Республикасы халык депутаты А.Ә.Камаловның гаризасын карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. 70 нче Ибраһимов территория сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутаты Камалов Алмаз Әгъләм улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының

Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре даими комиссиясе әгъзасы вазыйфаларыннан азат итәргә.

2. 70 нче Ибраһимов территория сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутаты Камалов Алмаз Әгъләм улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре даими комиссиясе әгъзасы итеп сайларга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 26 апрелендәге "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре даими комиссиясе составы турында"гы аннан соңгы үзгәрешләре белән карарына түбәндәге үзгәрешне һәм өстәмәне кертергә:

1 абзацта "14" санын "13" санына алмаштырырга; 2 абзацта "106 нчы ... сайлау округы" сүзләреннән соң: "Камалов Алмаз Әгъләм улы - 70 нче Ибраһимов территория сайлау округы" дип өстәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 26 апрелендәге "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре даими комиссиясе составы турында"гы аннан соңгы үзгәрешләре белән карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 абзацта "17" санын "13" санына алмаштырырга; 2 абзацта: "Камалов Алмаз Әгъләм улы - 70 нче Ибраһимов территория сайлау округы" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2038

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 459. "Татпромстройбанк" кертемчеләре мөрәҗәгатьләрен караганда һәм мәнфәгатьләрен яклаганда законнарны үтәү турында" Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбе хакында

Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбе буенча Татарстан Республикасы Прокуроры мәгълү-

матын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

“Татпромстройбанк” кертемчеләре мөрәҗәгатьләрен караганда һәм мәнфәгатьләрен яклаганда законнарны үтәү турында” Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 11 марты
№ 2039

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 460. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 24 мартындагы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 24 мартындагы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасының кайбер район, шәһәр судлары судьяларын сайлау турында.

2. “Лицензияләү турында” Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

3. “Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

4. “Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

5. “Файдалану хокукы продукция бүлешү турында килешүләр шартларында билгеләнә торган нефть ятмалары исемлеге хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

6. “Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

7. “Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге судлар турында” федераль конституциячел закон проекты

хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

8. Төрлесе.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 24 марты
№ 2045

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 461. Татарстан Республикасының кайбер район, шәһәр судлары судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 143 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Түбәндәгеләрне судьялар итеп сайларга:

Казан шәһәренең Авиатөзелеш район судына
Йосыпов Ризван Рәхимҗан улын;

Казан шәһәренең Мәскәү район судына
Якунин Сергей Николаевичны;

Казан шәһәренең Совет район судына:
Николаев Андрей Алексеевичны,
Габдуллина Гөлнара Әсхат кызын,
Галимов Рөстәм Камил улын;

Татарстан Республикасының Алексеевск район судына
Баранов Алексей Николаевичны;

Татарстан Республикасының Арча район судына
Вәлиева Гөлназ Дамир кызын;

Татарстан Республикасының Аксубай район судына
Гарифуллин Рәис Хаҗип улын;

Татарстан Республикасының Бөгелмә шәһәр судына:
Галимова Римма Әслах кызын,
Журавлев Таһир Хәсән улын;

Татарстан Республикасының Минзәлә район судына Аникина Вера Максимовнаны;

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә район судына Закиров Равил Хәмәтнур улын;

Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәр судына Лушникова Людмила Афанасьевнаны.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 24 марты
№ 2046

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 462. "Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен урнаштыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый байлыклар һәм табигатьтән файдалану комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 24 марты
№ 2047

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 463. “Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр хакында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

1. Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр хакында” Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен урнаштыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый байлыклар һәм табигатьтән файдалану комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 24 марты
№ 2048

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 464. “Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында файдалану хокукы бирелергә мөмкин булган нефть ятмалары исемлеге хакында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. “Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында файдалану хокукы бирелергә мөмкин булган нефть ятмалары исемлеге хакында” Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. “Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында файдалану хокукы бирелергә мөмкин булган нефть ятмалары исемлеге хакында”гы закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке юридик каршылыкларны

бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен урнаштыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 24 марты
№ 2049

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 465. "Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке юридик каршылыкларын бетерү, статьяларының үзара дөрес бәйләнешен урнаштыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 24 марты
№ 2050

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 466. "Россия Федерациясендә гомуми юрисдикция судлары турында" федераль конституциячел закон проекты хакында

"Россия Федерациясендә гомуми юрисдикция судлары турында" федераль конституциячел закон проектын карап,

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, әлеге закон проектының Россия Федерациясе Конституциясенә туры килмәвен һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килүен билгеләп үтә.

Россия Федерациясе Конституциясенең 5 статьясындагы 2 өлеше республиканың (дәүләтнең) үз конституциясе һәм законнары булуын беркетә. Шуның белән Россия Федерациясе Конституциясе Россия Федерациясе составындагы республиканың аерым статусын, аның дәүләт хакимиятенә, шул исәптән суд хакимиятенә тулы хокукын һәм үзенең хакими вәкаләтләрен суд тарафыннан яклау хокукын таный. "Россия Федерациясендә гомуми юрисдикция судлары турында" федераль конституциячел закон проекты республиканы дәүләт дип тануны читкә кага һәм ул моны танымаудан килеп чыга торган нәтиҗәләрне исәпкә алмый.

Татарстан Республикасы, үз Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының 1994 елның 15 февралендәге "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында"гы Шартнамәсе нигезендә демократик суверен дәүләт буларак, дәүләт хакимиятенең үз мөстәкыйль тармагына - Татарстан Республикасы Конституциясеннән, Татарстан Республикасы Югары арбитраж судыннан һәм гомуми компетенцияле судлар - Татарстан Республикасы Югары судыннан, Татарстан Республикасының район (шәһәр) судларыннан торган суд системасына ия.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 141, 142,152 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы суд органнарын мөстәкыйль формалаштыра, аларны оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибен законнар нигезендә билгели.

"Россия Федерациясе суд системасы турында" 1996 елның 26 декабрендә кабул ителгән Федераль конституциячел Закон һәм "Россия Федерациясендә гомуми юрисдикция судлары турында" федераль конституциячел закон проекты республика дәүләт хакимиятенең бер тармагы булган гомуми юрисдикциядәге судларны берьяклы рәвештә республика карамагыннан Россия Федерациясенә тартып алды, моның белән Россия Федерациясе Конституциясенең 5,73 статьяларын, шулай ук Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында 1994 елның 15 февралендә төзелгән Шартнамәне тупас бозды.

“Россия Федерациясе суд системасы турында” Федераль конституциячел Закон гамәлгә кергәнче, өлкә, край районнары (шәһәрләре) судларының судьялары Россия Федерациясе субъектларында сайланды.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. “Россия Федерациясендә гомуми юрисдикция судлары турында” федераль конституциячел закон проекты Россия Федерациясе Конституциясенә тәңгәл килми, Федерация республикаларын дәүләт буларак тануга каршы килә һәм аларны үз территорияләрендә суд хакимиятеннән читләштерә, шуның белән Россиядә федератив суд төзелешен кире кага.

2. Татарстан Республикасының түбәндәге принципиаль конституциячел позициясен расларга: Татарстан Республикасы суверен демократик дәүләт буларак дәүләт хакимиятенең бөтенлегенә ия, Татарстан Республикасы суд органнары системасының мөстәкыйль гамәлгә ашырылучы суд хакимияте аның бер тармагы булып тора.

3. Судьяларны республикаларның дәүләт хакимиятенең иң югары вәкиллекле (закон чыгару) органнары тарафыннан элек гамәлдә булганча билгеләп кую тәртибен торгызуны максатка ярашлы дип санарга.

4. Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) органнарына әлеге карарны хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

5. Әлеге карарны Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советына һәм Дәүләт Думасына, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, Россия Федерациясенең Судьялар советына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 24 марты
№ 2051

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 467. “Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чараларын финанслау хакында” Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Әлеге мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматын игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 24 марты
№ 2052

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 468. Акча кертүчеләрнең кертемнәрен кайтару турында “Промстройбанк” банкының конкурслы идарәчесе мәгълүматы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Әлеге мәсьәлә буенча “Промстройбанк” банкының конкурслы идарәчесе мәгълүматын игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 24 марты
№ 2053

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 469. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе эшен дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе эшен 1999 елның 11 мартында Казан шәһәрендә дәвам итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 марты
№ 2011

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 470. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе көн тәртибенә түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1. “Татарстан Республикасының Законнар җыентыгы турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.
2. 1999-2000 елларга “Татарстан яшьләре” Дәүләт

программасы проекты турында.

3. "1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотиклардан явыз ниятләрдә файдалануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы торуның комплекслы чаралары" Республика максатчыл программасы проекты турында.

4. Россия Федерациясе Җинаять кодексының 329 статьясына үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре комиссиясе эшенең хисабы турында.

6. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды судьяларын сайлау турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 марты
№ 2012

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 471. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе каравына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карар проектларын кертергә:

1."Татарстан Республикасы Законнар җыентыгы турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

2.1999-2000 елларга "Татарстан яшьләре" Дәүләт программасы проектын эшләүне дәвам итү турында.

3. "1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотиклардан явыз ниятта файдалануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы торуның комплекслы чаралары"

Республика максатчан программасы проектын эшләүне дәвам итү турында.

4. Россия Федерациясе Җинаять кодексының 329 статьясына үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре даими комиссиясе эше турында хисап.

6. Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды судьяларын сайлау турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 марты
№ 2013

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 472. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы язгы сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы язгы сессиясенең чираттагы утырышын 1999 елның 24 мартында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 марты
№ 2014

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 473. 1999 елның 24 мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 24 мартында Татарстан Республикасы Дәүләт

Советы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. "Лицензияләү турында" Татарстан Республикасы законын кабат карау турында.

2. "Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

3. "Продукцияне бүлешү турында килешүләр хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

4. "Файдалану хокукы продукция бүлешү турында килешүләр шартларында билгеләнә торган нефть ятмалары исемлеге хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

5. "Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 марты
№ 2015

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 474. 1999 елның 24 мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 24 мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карарлары проектларын кертергә:

1. "Лицензияләү турында" Татарстан Республикасы законын кабат карау турында.

2. "Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

3. "Продукцияне бүлешү турында килешүләр хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам

иту турында.

4. “Файдалану хокукы продукция бүлешү турында килешүләр шартларында билгеләнә торган нефть ятмалары исемлеге хакында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам иту турында.

5. “Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам иту хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 марты
№ 2016

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 475. Җирле үзидарә органнары вәкилләренең республика җыелышын уткәрү көне турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

“Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары вәкилләре җыелышын үткәрү вакытын күчерү турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 18 февралендәге 2008 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Республикада җирле үзидарәне булдыру проблемаларын һәм аны тагын да үстерү перспективаларын тикшерү буенча җирле үзидарә органнары вәкилләренең республика җыелышын 1999 елның 12 мартында Казан шәһәрендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында үткәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 марты
№ 2021

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 476. "Гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыклары турында" Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау нәтиҗәләре турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы бәяләмәләрен исәпкә алып "Гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыклары турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләп бетерү өчен кире кайтарырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 марты
№ 2025

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 477. Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 12 февралендәге XVIII пленар утырышында әйтелгән тәкъдимнәр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре адресына Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 12 февралендәге XVIII пленар утырышында әйтелгән тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар

планын расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты адресына Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 12 февралендәге XVIII пленар утырышында әйтелгән тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына җибәрергә (2 нче кушымта).

3. Чаралар планының үтәлеше нәтиҗәләре һәм тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре турында бер айдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы халык депутатларына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына хәбәр итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре В.Н.Липужинага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 марты
№ 2029

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 478. Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 18 февралендәге утырышында әйтелгән тәкъдимнәр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре адресына Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 18 февралендәге утырышында әйтелгән тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты адресына Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999

елның 18 февралендәге утырышында әйтелгән тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына җибәрергә (2 нче кушымта).

3. Чаралар планының үтәлеше нәтиҗәләре һәм тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре турында бер айдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы халык депутатларына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына хәбәр итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре В.Н.Липужинага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 марты
№ 2030

# III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 479. Татарстан Республикасының җиңел һәм агач эшкәртү промышленносте предприятиеләренә дәүләт булышлыгы күрсәтү чаралары турында

Җиңел һәм агач эшкәртү промышленносте предприятиеләренең финанс-икътисад торышын тотрыклыландыру, югары сыйфатлы кулланылыш товарлары җитештерүнең күләмен арттыруны тәэмин итү, республика товар җитештерүчеләренә ярдәм итү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Промышленность предприятиеләре ассоциациясенең чимал сатып алу һәм әзер продукция сатудагы сезонлы үзенчәлеккә ия җиңел һәм агач эшкәртү промышленносте предприятиеләренә өстенлекле салым режимы кертү тәкъдимнәрен хупларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы шәһәр һәм район хакимиятләре башлыкларына җиңел һәм агач эшкәртү промышленносте предприятияләре җитештергән һәм (яки) алар тарафыннан сатылган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүнең, шул исәптән аванс белән салым түләүгә карата да, сезонлы булуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Республика бюджетына, җирле бюджетларга салымнар һәм җыемнарны түләп бетерү срокларын үзгәртү буенча законга яраклаштырылган карарлар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлегә Указга мөнәсәбәте булган предприятиеләрнең исемлеген ачыкларга.

4. Дәүләт хакимиятенең җирле органнарына, җирле үзидарә органнарына җиңел һәм агач эшкәртү промышленносте предприятиеләренә өстәмә салым өстенлекләре бирүне тәкъдим итәргә.

5. Бу Указның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Указ басылып чыккан көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан, Кремль
1999 ел, 2 март
№УП–134

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 480. Авиация промышленносте эшләре буенча Республика советы төзү турында

Татарстан Республикасы авиация предприятиеләренең эшләрен тотрыклыландыру, аларның җитештерү, фәнни һәм техник куәтләреннән нәтиҗәле файдалану, төрдәш тармакларда һәм тулаем республика икътисадында производствоны үстерү максатларында **карар бирәм**:

1. Авиация промышленносте эшләре буенча Республика советын төзергә.

2. Авиация промышленносте эшләре буенча Республика советы турында Нигезләмәне расларга (кушымтада бирелә).

3. Авиация промышленносте эшләре буенча Республика советының түбәндәге составын расларга:

| | |
|---|---|
| Мөхәммәтшин Фәрид Хәйрулла улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе - совет рәисе (килешенү буенча) |
| Киреев Назир Талип улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры киңәшчесе - совет рәисе урынбасары |
| Кәримов Әнвәр Зәки улы | Татарстан Республикасы икътисад һәм промышленность министрының беренче урынбасары |
| Галиев Марат Һади улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисади үсеш һәм реформалар мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе (килешенү буенча) |

| | |
|---|---|
| Исхаков Камил Шамил улы | Казан шәһәре хакимият башлыгы |
| Ибәтуллин Фоат Гомәр улы | Казан шәһәре Авиатөзелеш район хакимияте башлыгы |
| Хәйруллин Наил Гомәр улы | С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация производство берләшмәсе генераль директоры |
| Лаврентьев Александр Петрович | "Казан вертолет заводы" ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры |
| Павлов Александр Филиппович | "Казан моторлар төзү производство берләшмәсе" ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры |
| Дивавин Геннадий Валерьевич | "Электроприбор" Казан заводы" дәүләт унитар предприятиесе директоры |
| Апаков Рәшид Усман улы | "Радиоприбор" Казан заводы" дәүләт унитар предприятиесе дирек торы |
| Александров Василий Егорович | "А.Н.Туполев исемендәге Авиация фәнни-техник комплексы" ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешенү буенча) |
| Симонов Михаил Петрович | "Сухой исемендәге Тәҗрибә-конструкторлык бюросы" ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешенү буенча) |

4. Указ кул куйган көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 2 март
№УП–135

Эчтәлек